| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>МУСЛЮМОВСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН<br><br>**СОВЕТ НИЖНЕТАБЫНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ** | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br><br>**ТҮБӘН ТАБЫН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |
|---|---|---|

*Юрид.адрес: 423977, РТ, Муслюмовский район, с. Нижний Табын, ул. Молодёжная, 10*
*Факт.адрес: 423977, РТ, Муслюмовский район, с. Верхний Табын, ул. Тукая, 19б*
Тел./факс: 8-85556-32874/Элект. адрес: Ntab.Mus@tatar.ru
ИНН 1629001040, КПП 162901001, ОГРН 1021605558435, ОКТМО 92642450


**Югары Табын авылы** **24 декабрь, 2019 ел**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТҮБӘН ТАБЫН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ III ЧАКЫРЫЛЫШ XLV УТЫРЫШЫ**

**К А Р А Р № 1**

**Түбән Табын авыл җирлеге Советының 10 нчы декабрь 2018 нче елның № 3 номерлы «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә, Түбән Табын авыл җирлеге Советы **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлеге Советының 2018 елның «10» декабрь «Җир салымы турында» 3 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Салым ставкалары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

1) түбәндәге җир кишәрлекләренә карата 0,3 процентта:

авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яисә торак пунктларда авыл хуҗалыгы куллану зоналары составындагы җирләргә кертелгән һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен кулланыла торган җир кишәрлекләренә;

торак-коммуналь комплексның торак фонд һәм инженерлык инфраструктура объектлары белән биләп алынган (торак-коммуналь комплексының торак фондына һәм инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлештән тыш) яки торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) (эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш) җир кишәрлекләренә;

эшкуарлык эшчәнлегендә шәхси хуҗалык, бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән), шулай ук «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә;

<u>оборона, иминлек һәм таможня ихтыяҗларын тәэмин итү өчен бирелгән Россия Федерациясе законнары нигезендә әйләнештә чикләнгән затлар;</u>

2) шәхси хуҗалык алып бару, бакчачылык, яшелчәчелек һәм терлекчелек, шулай ук дача хуҗалыгы өчен бирелгән җир кишәрлекләренә карата 0,1% ;

3) 1 - 3 категорияле гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен бирелә торган кишәрлекләргә карата 0,05%.

4) Торак пунктлар җирләре өлешендә сәнәгать һәм коммуналь хуҗалык объектлары астындагы җир кишәрлекләренә карата 0,8 %;

5) административ, офис биналары, мәгариф, фән, сәламәтлек саклау, социаль тәэмин итү объектлары җир кишәрлекләренә карата 0,6% ;

6) башка җир кишәрлекләренә карата 1,5%.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да соңга калмыйча үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан җир салымын исәпләү белән бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

*Татарстан Республикасы*
*Мөслим муниципаль районы*
*Түбән Табын авыл Советы рәисе,*
*җирлек башлыгы* *Р.Ш. Кыяметдинов*